«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2021 елның 22 декабре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыенының 2021 елның 20, 21, 22 декабрендә уздырылган этаплары нәтиҗәләре буенча ,түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), 2022 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- Пионер урамы буенча эчке юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү.).»

Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 591 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 308 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенының 302 катнашучысы тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 6 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1.«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес , дип танырга.

2.Түбәндәге сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), 2022 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?

-- Пионер урамы буенча эчке юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү.)»

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), 2022 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

-- Пионер урамы буенча эчке юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү.)»

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы, гражданнар җыенында рәислек итүче

И. Т. Гыйниятов